**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Зур Әтрәч авыл җирлегенең Зур Әтрәч торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Зур Әтрәч авыл җирлегенең Зур Әтрәч торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Зур Әтрәч авыл җирлегенең Зур Әтрәч торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда 1200 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Зур Әтрәч авылында авыл эчендәге юлларны төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Зур Әтрәч авылында лампалар, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру;
- Зур Әтрәч авылында чишмәне төзекләндерү;
- Зур Әтрәч авылында күл территориясен төзекләндерү;
- Зур Әтрәч авылында Тукай урамындагы балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу;
- Зур Әтрәч авылында һәлак булган сугышчыларга куелган обелиск территориясен төзекләндерү

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **И.Ш. Юнусов**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Зур Әтрәч авыл җирлеге башлыгы** **И.Ш. Юнусов**